**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Гулкин авыл җирлеге Советы**

**№83** **28.11.2022 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 20 номерлы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль закон, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 320-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 18 номерлы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советы карарына (2022 елның 09 мартындагы 57 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.20 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- әлеге нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта, физик затның яисә юридик затның - сатулашулар җиңүчесенең исеме, аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган затның исеме.»;

1.2. 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Муниципаль милек бәясе турында тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан сатулашулар барышында ачык белдерелә. Сатулашу нәтиҗәләре буенча аукционда җиңүче белән килешү төзелә.

Аукционда катнашуга гаризаны аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган бер генә зат биргән очракта, килешү муниципаль милекне сатуның башлангыч бәясе буенча шундый зат белән төзелә.

Аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат аукцион шартнамәсе төзүдән баш тарткан очракта аукцион узмаган дип танылa.»;

1.3. 5.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Әлеге нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында

билгеләнгән очракта, аукционда катнашучыны җиңүче яки бердәнбер катнашучы зат дип тану турында хәбәрнамә, аукционга йомгак ясаган көнне, әлеге нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән очракта, җиңүчегә йә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган затка җибәрелә.»;

1.4. 5.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Аукционда җиңүче йә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат, әлеге нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән очракта, мөлкәтне сатып алу-сату шартнамәсе төзүдән баш тартканда, алдан бирелгән акча (задаток) аңа кире кайтарылмый һәм ул күрсәтелгән килешүне төзү хокукын югалта.»;

1.5. 5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Алдан бирелгән суммалар (задаток) аукционда катнашучыларга, җиңүчедән яисә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган заттан тыш, әлеге нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән очракта, аукционга йомгак ясалганнан соң биш көн эчендә кайтарыла.»;

1.6. 5.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.13. Аукционда җиңүче йә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат белән аукционга йомгак ясаган көннән соң биш эш көне эчендә, әлеге нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән очракта, сату-алу килешүе төзелә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **С.Д.Инькова**